**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2024елның 16 апреле 542/ПИК

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Державино авыл җирлегендә кадастр номеры 16:24:060201:1418 булган җир кишәрлегенең бер өлешенә гавами сервитут билгеләү турында.**

РФ Җир кодексының 23 маддәсенең 1 пункты 4 пунктчасы нигезендә, Лаеш муниципаль районының 2024елның 12 гыйнварындагы 280-АН номерлы Державино авыл җирлеге башкарма комитеты мөрәҗәгате, 2024 елның 21 февралендәге «Камская новь» газетасындагы басмасы, Лаеш муниципаль районы сайтындагы https:// laishevo.tatarstan.ru/hodataystva.htm сылтамасы буенча хәбәрләр нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Державино авыл җирлегендә кадастр номеры16:24:060201:1418 булган җир кишәрлегенең бер өлешенә 16:24:060201:1027 кадастр номерлы православие зиратына килү һәм керү юлын оештыру максатларында ачык сервитут билгеләргә, билгеләү срогы - чикләнмәгән.

2. Татарстан Республикасы Державино авыл җирлегендә, Лаеш муниципаль районында урнашкан кадастр номеры 16:24:060201:1027 булган православие зиратына килү һәм керү максатларында бирелгән гавами сервитутның чикләрен расларга.

3Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына, законнарда билгеләнгән тәртиптә, әлеге карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә:

- әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга;

4. Лаеш муниципаль районының Державин авыл җирлеге башкарма комитетына:

- әлеге карарның күчермәләрен Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, җир кишәрлекләренең хокук иясенә җибәрүне тәэмин итәргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Э. В. Хисмәтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**